ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2018 ел № 23/7

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм «Россия Ффедерациясенең Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым законлылык актларына үзгәрешләр кертү һәм 2018 елда федераль бюджет үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законнын 6 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 434-ФЗ санлы Федераль зваконга нигезләнеп

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6, 2015 елның 22 октябрендәге 2/14, 2016 елның 24 февралендәге 6/6, 2017 елның 24 октябрендәге 20/5 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7.1 маддәсенең 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әлеге маддәнең нигезләмәләре законнар белән билгеләнгән салымнар һәм җыемнар Россия Федерациясе законнары нигезендә производствода бәхетсезлек очракларын һәм профессиональ авыруларны иминиятләштерү, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм Россия Федерациясенең таможня турындагы законнарына кагылмый.»;

2) 8 маддәдә:

– 12 өлешнең тугызынчы абзацында «субсидияләр бирү турында килешүләргә» сүзләреннән соң «һәм (яйсә) аларны бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга,» сүзләрен өстәргә;

– 14 өлешнең өченче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Әлеге маддәнең 14 өлеше беренче абзацында каралганча субсидияләр биргәндә, аларны бирү турында килешүгә һәм (яйсә) муниципаль хокукый актка, шулай ук бу килешүләр нигезендә үзара йөкләмәләрне билгеләүче килешүгә кертелүче мәҗбүри шарт - субсидия бирүче бюджет акчаларын төп бүлеп бирүче һәм муниципаль финанс контроле органнары белән берлектә субсидия алучылар һәм субсидия алу турында килешү нигезендә подрядчы, хезмәт күрсәтүче затларның, субсидия алучының субсидия бирүнең шартларын, максатын һәм тәртибен, алган акчаларга чит ил валютасы( Россия Федерациясенең валюталар белән эшләү турындагы законнарынна таянып югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал, комплектлаштыру эшләнмәләре, шулай ук муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тертиптә муниципаль учреждение булмаган, коммерцияле булмаган оешмалардан тыш) алмавын контрольдә тоту».

3) 38 маддәнең 4.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан әлеге маддәнең 4 өлешенә нигезләнеп хисаптагы финанс елында ихтыяҗ булмау сәбәпле кулланылмаган бюджетара трансфертлар булуы (булмавы), аларны алынган бюджетларына кире кайтару күрсәтелгән средстволар бюджетка кергән көннән башлап 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, шәһәр бюджеты средствлоларының баш администраторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә формалаштырылган һәм бирелгән бюджет хисабына туры китереп башкарыла.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев